МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.09.2020 г.Казань № 634

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 6 октяберендә 6876 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2017 елның 21 мартындагы 163 номерлы «2017 - 2020 елларда тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибен раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2017 - 2020 елларда тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 21 мартындагы 163 номерлы боерыгына кертелә торган кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 10 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.А.Зарипова

Расланган
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
16.09.2020 ел. № 634 боерыгы белән

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау Министрлыгының 2017 ел 21 мартындагы 163 номерлы
боерыгына кертелә торган үзгәрешләр
«2017-2020 елларда тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яштәге гражданинның
яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибен
раслау турында»

Исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яштәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибен раслау турында»;

преамбуладагы «Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яштәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаж дип танылган, эшкә яраксыз гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

1 пункттагы «2017-2020 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

Күрсәтелгән боерык белән расланган тәрбиягә алучы гаиләдә өлкән яштәге гражданның яшәү шартларын 2017 елда ай саен тикшерү уздыру тәртибендә (алга таба - Тәртип):

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яштәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибе»;

Тәртипнең 1 пунктында:

«2017-2020 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яштәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаж дип танылган, эшкә яраксыз гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 2 пунктындагы «Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яштәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаж дип танылган, эшкә яраксыз гражданнар өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтада:

нумерацияле исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибенә 1 нче кушымта»;

«Өлкән кеше өчен тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» сүзләрен «Өлкән яшьтәге, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган, эшкә яраксыз граждannar өчен тәрбиягә алучы гаиләләр төзү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипкә 2 нче кушымтада нумерацияле исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәрбиягә алган гаиләдә өлкән яшьтәге гражданинның яшәү шартларына ай саен тикшерү уздыру тәртибенә 2 нче кушымта».